| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ КУРНАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ КӨРНӘЛЕАВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

Коры Көрнәле ав.

17.01.2019 №102

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районы**
**Көрнәле авыл җирлегендә**
**муниципаль хезмәт турындагы**
**Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

Гамәлдәге законнарга, шу исәптән “Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелекне алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында”гы 29 июль, 2017 ел, 217-ФЗ санлы Федераль закон Нигезләмәләренә туры китерү максатында

**Көрнәле авыл җирлеге Советы карар бирде**:

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Көрнәле авыл җирлегендә Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Көрнәле авыл җирлегенең 26 июнь, 2018 ел, 81 нче Карары белән расланган муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә түбәндәге эчтәлектәге үзгәрешләрне кертергә:

12.1 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

2)эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шәхсән яки ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә, коммерция оешмасына яки коммерциячел булмаган оешмага идарә итүдә катнашырга (сәяси партиягә идарә итүд әкатнашудан, бушлай нигездә җирле үзидарә органында булдырылган башлангыч профсоюз оешмасының сайлап куела торган органына идарә итүдә катнашудан, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратына идарә итүдә катнашудан, съездда (конференциядә) катнашудан яки иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативы, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативы, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтенең гомуми җыелышында катнашудан, бушлай нигездә күрсәтеп кителгән коммерциячел булмаган оешмаларга (сәяси партия һәм профессиональ берлек органыннан, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында

булдырылган башлангыч профсоюз оешмасыннан кала) идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында катнашырга яки түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль органнары составына яллаучы вәкилнең (эш бирүченең) муниципаль хокук акты билгеләгән тәртиптә алынган рөхсәте белән керү.

2.Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Көрнәле авыл җирлегенең 19 ноябрь, 2018 ел, 97 нче Карарын көчен югалткан дип санарга.

3.Әлегекарарны Көрнәле авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Көрнәле авыл җирлеге Советы бинасындагы мәгълүмат тактасына урнаштырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземдә калдырам.

**Алексеевск муниципаль районы**
**Көрнәле авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **Х.А.Медведев**